СОВЕТ БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ                                                  КАРАР

24.10.2022                                               № 23-118

с. Большие Меми

Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авылы җирлеге җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт хакы чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә, Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Уставы белән,

Югары Ослан муниципаль районының
Олы Меми авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә, даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына депутатларга, сайланулы вазыйфаи затларга хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына Олы Меми авыл җирлеге Советының 2020 елның 28 октябреннән 2-15 карары белән расланган түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге  Советының
2022 елның «24» октябреннән
23-118 карарына

1 кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми  авыл җирлеге  җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| Вазифа атамасы | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет секретаре | 15904 |

1.2. Карарга 12нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы

Олы Меми авыл җирлеге Советының
2022 елның «24» октябреннән
23-118 карарына
2 нче кушымта

Олы Меми авыл җирлеге башлыгының акчалата түләү күләме

| Вазифа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы | 16389 |

2. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Советының закон һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районының
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г.А. Фомина